**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге составына керүче Сәрдек авылы торак пунктында узган**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

15 ноябрь 2020 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35нче маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Сәрдек авылында гражданнар җыены карар итте:

1. 2021 елда, Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең Сәрдек авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр кешегә, (I төркем инвалидларга, үз-үзләренә хезмәт күрсәтә алмый торган гражданнарга, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче ялгыз ата-аналарга (законлы вәкилләргә, Россия Армиясе сафларында вакытлы һәм контрактлы хезмәте үтүче егетләргә үзара салым суммасының 90 проценты күләмендә ташлама каралган) 750 (Жиде йөз илле) сум күләмендә салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкару өчен файдаланырга:

- материаллар сатып алу һәм Сәрдек авылы зираты коймасын төзекләндерү;
- комплектлау җайланмалары булган ике янгын колонкасы сатып алу;
- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Пыжмара авыл җирлеге "муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре" н эшләтү.

3. Җыен нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Балтач муниципаль район сайтында (http://baltasi.tatarsta.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Балтач муниципаль районы
Пыжмара авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Заляев